**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12416**
**22.12.2023**

Башкарма комитетның «2021-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5735 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2021-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5735 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 10 сентябрендәге 5967 номерлы, 2022 елның 25 мартындагы 1623 номерлы, 2022 елның 27 маендагы 2715 номерлы, 2022 елның 14 июлендәге 3557 номерлы, 2023 елның 24 мартындагы 2091 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13; «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге өлкәсендә башка мәсьәләләр» 03.14 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә: 2021 ел – 97 922,81 мең сум, 2022 ел – 101 822,2 мең сум, 2023 ел – 122 027,0 мең сум, 2024 ел – 86 856,8 мең сум.»;

2) «2021-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | Тормышка ашыру чорында барлыгы мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел мең сум | 2022 ел мең сум | 2023 ел мең сум | 2024 ел мең сум | |
| | Муниципаль бюджет | 97 922,81 | 101 822,2 | 122 027,0 | 86 856,8 | 408 628,81 |
| | Федераль бюджет | | | | | |
| | Республика бюджеты | | | | | |
| | Башка чыганаклар | | | | | |
| | Барлыгы | 97 922,81 | 101 822,2 | 122 027,0 | 86 856,8 | 408 628,81»; |

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

2021-2024 елларга программаны финанслау күләме 408 628,81 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2021 ел – 97 922,81 мең сум, 2022 ел – 101 822,2 мең сум, 2023 ел – 122 027,0 мең сум, 2024 ел – 86 856,8 мең сум.»;

- 8 бүлектә:

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3.7. ҖТСПны карап тоту | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2021-2024 | | | | | | | 91 504,67 | 93 833,9 | 90 193,7 | 76 746,8»; |

3.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3.14. «Куркынычсыз шәһәр» АПК өчен элемтә каналлары хезмәтләре күрсәтү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2021-2024 | | | | | | | 6 398,14 | 4 851,6 | 26 353,3 | 9 910,0»; |

«Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «БАРЛЫГЫ: | 97922,81 | 101 822,2 | 122 027,0 | 86 856,8» |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов